**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2020елның 4 августы 1515номер

**КАРАР**

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның исемлеген билгеләү хакында» 2018 елның 25 июлендәге 2609 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты карарына өстәмәләр кертү турында**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020елның 24 апрелендәге 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә карар бирәм**:**

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның исемлеген билгеләү хакында» 2018 елның 25 июлендәге 2609 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының карарына, Лаеш муниципаль районында административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.16 статьясы буенча өстәмәләр кертергә (кушымта).
2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.П. Шитовка йөкләргә.

**Җитәкче** **И.Ф.Зарипов**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы
Башкарма комитетының 2020 елның 4 августындагы
1515 номерлы карарына кушымта

**Лаеш муниципаль районында**
**административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның өстәмә исемлеге**

| ТР КоАП маддәсе | Вазыйфаи затлар исемлеге |
|---|---|
| **ТР КоАП 2.16 маддәсе.** Балигъ булмаганнарга тәмәкесез никотинлы продукцияне, никотинны илтеп җиткерүнең электрон системаларын сатуны, шулай ук балигъ булмаганнарны тәмәкесез никотинлы продукцияне куллануга җәлеп итүне тыюны бозу. | «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының административ-техник инспекциясе» МКУ башлыгы;<br>«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының административ-техник инспекциясе» МКУ башлыгы урынбасары;<br>«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының административ-техник инспекциясе» МКУ баш белгече;<br>«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Административ-техник инспекциясе» МКУнең әйдәп баручы белгече. |